РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 05 » 06 2023 г. №807

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 10.02.2017 № 14 карары белән расланган, Ютазы муниципаль районы юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 196-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 31.12.2022-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы хөкүмәт комиссиясе турында» 2006 елның 30 октябрендәге 529 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 февралендәге 14 номерлы карары белән расланган Ютазы муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссиясе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе Президенты, Татарстан

Республикасы Башлыгы – Рәисе, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карарларына һәм күрсәтмәләренә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы” Уставына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга .

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары итеп йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина